Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге Советының чираттан тыш утырышы

# КАРАРЫ

2019 елның 30 гыйнвары № 122

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге башлыгы, Кәвәл авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 17 октябрендәге 940 номерлы «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайлап куела торган вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында», Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары белән расланган «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайлап куела торган вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында » карарлары нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге 93 номерлы «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге башлыгы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре хезмәтенә түләү турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтада «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге башлыгының хезмәте өчен түләү» 2 нче пунктта «4,65» санын «6,72» санына алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге Советының 2018 елның 25 маендагы 81 номерлы «Кәвәл авыл җирлеге башлыгына ай саен премия бирү турында» гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны икътисадый үсеш, бюджет, салымнар һәм финанслар мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Кәвәл авыл җирлеге башлыгы А.Ф.Фәйзрахманов

СОВЕТ КОВАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ